Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл Советы

КАРАРЫ

27 октябрь 2022 ел №58

Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфа окладларының акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә

Иске Михайловка авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына(Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 61 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 9 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарга кушымтаның 6 пункт 2 пунктчасында, 7 пункт 3 пунктчасында «(авырлыгы, киеренкелеге, хезмәттә югары казанышлары, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян тәргә:

Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт
Окладлары күләме

| «Вазыйфа исеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| | 12 группа |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 16383,00 |
| Авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 15905,00 |

1.3. 2 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре»

| «Вазыйфаисеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| | 12 группа |
| Башлык | 16390,00 |
| Башлык урынбасары | 11959,00 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле финанс чыгымнары белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджета каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 йорты; Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а нчы йорт; территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» Интернет-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Михайловка авыл җирлеге
башлыгы урын басары И.М.Абдуллин